# ҖИҢҮ

КӨНЕ


ПРОЛЕТАРИИ
1941-1945

Минем әбиемнең әти-энисе һәм бабамның әти –әнисе дә Бөек Ватан сугышында катнашканнар. Алар сугышка ять-яшь егетләр, кызлар, туган җирләрен саклау өчен, фронтка китәләр. Минем ике бабамның әтиләре дә сугышның башынан алып ахырына кадәр булганнар. Әбиләрнең әниләре тылда армый-талмый хезмәт иткәннәр. Тылда калганнар да солдатлар өчен җылы оекбашлар, бияләйләр бәйлиләр. Җиңү өчен дип, бар тырышлыкларын куялар. Сугыш бик күп гаиләләргә кайгы, ачы күз яшьләре китерә.



Бөек Ватан сугышының тынганына җитмеш елдан артык вакыт үтте. Мин үземдә, әти-әниемдә сугыш чорын күрмәдек. Бу кан койгыч сугыш турында ишетеп кенә беләбез. Сугыш дип әйтүгә, минем күз алдыма җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, ятим балалар килеп баса.

*Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт китерә.*

*Мин үземнең сугышта булган, Ватанны саклаган туганнарым турында сөйләп китәм. Бу минем әниемнең әбиләре: Замалеева Сөмбелә Фатыховна һәм Билданова Гатифя Фассаховна; бабайлыры Замалеев Фахрислам Хазисламович һәм Билданов Валимхамет Махмутович; әтиемнең әбиләре: Галимова ХадичәВалиахметовна Һәм Маняпова Сара Халиулловна; бабайлары Галимов Бәдертдин Шамарданович, Маняпов Зайдулла Насибуллович турында булыр.*

*Әбиләр тылда хезмэт иткэн, ул ваытта әле алар минем әти –әнием кебек бик яшь булганнар. Тормышларын кырып җибәргән яшь гаилә булганнар. Ләкин яшь булуларына карамастан дүрт бабайның әтиләре дә фашистлардан илне сакларга дип хатыннарын, нәни балагарын калдырып чыгып китәләр. Алар җиңү өчен, үзләренең өйләрендә, балалары янында булу бәхетен яулау өчен киттеләр. Үзләрен аямыйча, хәтта гомерләрен дә кызганмыйча көрәштеләр алар. Аларның һәр берсенең үз тарихы, үз күзаллавы һәм шатлыклы да, кызганычлы да мизгелләре бар.*



Бильданов Валимхамет

Махмутович

(15.10.1908 – 10.06.1984)

Бөек Ватан сугышында

1941 – 1946 елларда булган



*Минем бабамның бабасы сугышта 1941 – 1946 елларда булган. Ул 627 стрелковый полкта стрелок – автоматчик һәм ручной пулеметчик специальностендә хезмәт иткән. Ул шул чагында башына яраланган. 1942 елның 19 июннән һәм 1945 нчы елның 3 маена кадәр ул пленда (кулда) була. Бу хәл Польшаның – Фельцы шәһәре территориясендә була. Аның өчен сугыш бары тик 1946 елда гына тәмамлана. Сугыштан соң әле ул тиз генә өйгә кайтмый, ә үзенең часте белән халык тормышын торгызуда, шәһәрләрне төзекләндерүдә актив катнаша. Ул Семфирополь шәһәрендә юллар төзүдә катнаша, зур-зур ташлар ташый, километрлап баткаклыкта юл салалар.*

## БҮЛӘКЛӘРЕ

Прадедушка был награжден: «За Победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941-1945гг.», знаком «25 лет Победы в Великой Отечественной войне», 50, 60 лет Вооруженных сил СССР, юбилейными медалями 20, 30 лет Победы в Великой Отечественной войне.

# БИЛЬДАНОВА – САДРЕТДИНОВА ГАТИФЯ ФАССАХОВНА

Минем әбиемнең әбисе 1915 елның *3 апреля Хусаиново-Благодаровка авыланда дөньяга килә.*

*Гатифя әби колхозда кыр бригадасында эшли. Ул кәбестә, кишер һәм төрле яшелчәләр үстерә. Болар барысыда сугыш кырларына китә торган азыклар була. Кыр авыл артында була. Хәзеге чишмә тирәләре, авылдан ерак эшләргә кирәк була. Суны Кондырча елгасыннан ташып үстерәләр алар, барысы да кул эше. Сугыштан соң аның әти –әнисе үлеп китә һәм ул сеңел-энеләрен тәрбияли, алар өчен әни –әтисен алыштыра. Бабай белән кушылып алар 6 бала үстерәләр.*

*Гатифә әбиебез 1977 елда үлеп китә. Аңа бары 62 яшь була.*







# ЗАМАЛИЕВА (САДЫКОВА) СӨМБЕЛӘ ФАТЫХОВНА

Бу минем әниемнең

әбисе була . Ул 1925 нче елның 29 октябрнедә туган. Аның туган ягы Арча районы Түбән курса авылы. Сугыш елларында әле ул яшь кыз була. Ул әтисен сугышка озатып, әнисе белән бергәләп колхозда эшли. Сугыш беткәч бабай белән кушылып 7 бала үстерәләр.

1984 елның 24 июнендә 58 яшендә үлеп китә.


Фамилия ЗАМАЛИЕВ
Имя ФАХРИСЛАМ
Отчество ХАЗИСЛАМОВИЧ
Пол МУЖ. Дата рождения 29.06.1924
Место рождения Д. ВЕРХНЯЯ КОРСА АРСКОГО РАЙОНА ТАССР
92 04 000852

**(29.06.2924-07.01.2015)**

Әниемнең бабасы Фахрислам бабй сугышка 17 яшендә китә. Ул 767 стрелковый полкында хезмәт итә. 1943 елның 21 январендә авыр яралангаен була. Ул Ленинград битвасында да катнаша. “За победу над Германией” “50 лет победы”, “ 60 лет Победе”, “50 лет ВООР сил СССР” медальләре белән бүләкләнә. Аның вафат булганына әле быры 1 ел гына узды. Мин аны хәтерлим: ул безнең белән шаярып биеп йөри иде. Урыннары җәннәттә булсын.

# ГАЛИМОВ БАДЕРТДИН ШАМАРДАНОВИЧ (18.09.1916-26.09.1991)




Әтиемнең әнисенең әнисе Галимова Хадичә Валиахметовна (22.04.1920-06.12.2005) сугышта катнашмасада, тылда хезмәт итә. Яшь кызлар булуына карамастан алар авыр эштә эшләгәннәр-урман кискәннәр. Әтиемнең Әнисенең әтисе Галимов Бәдертдин Шамарданович сугышка 1939 елны китә. Сугыштан бары 1947 елны гына кайта. Ул Румыния, Белорусия, Чехословакия, Венгрия илләрен дошманнан азат итүдә катнаша. Орден за отвагу, За Родину белән бүләкләнә. Аның барлыгы 12 медале була. Алар Хадичә әби белән кушылып 5 бала үстерәләр. Бәдертдин бабай бик оста тимерче була, аның тимер сугып ясаган әйберләрен әби әле дә саклый.


Әтиемнең әтисе Файзулла бабайемның әти әниләре дә сугашта катнашканнар. Бабайның бабасы: Маняпов Зайдулла Насибуллович (18.02.1928-03.1975) сугышта аягын кистергән, сугыш беткәч исән кайткан. Алар яшьли сугышның ачысын да течесен дә күргәннәр.

Бабайның әнисе Маняпова Сара сугышка үз теләге белән киткән. Ул Подмосковьеда окоплар казуда катнашкан. Шунда яраланып озак кына госпитальдә яткан. Сугыш беткәч Зайдулла бабай белән кушылып 6 бала үстергәннәр.

## МАНЯПОВА САРА ХАЛИУЛЛОВНА (18.01.1921-26.09.199)



# НЕЛЬЗЯ НАУЧИТЬСЯ ЛЮБИТЬ ЖИВЫХ, ЕСЛИ НЕ УМЕЕШЬ ХРАНИТЬ ПАМЯТЬ О ПАВШИХ . . .



Сугышлар булмый корбансыз.

Ансыз – юк Җиңү туе.

Ә без үлгәннәр алдында

Бурычлы гомер буе.

Еллар үткән саен сугыш ветераннары саны кими бара. Без алар алдында түләп бетермәслек бурычлы. Киләчәктә күкләребез гел дә аяз, тормышыбыз тыныч булсын иде!

